ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 сентябрь 2015 ел № 5382

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлеген формалаштыру, алып бару һәм раслау тәртибе турында нигезнамәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 69.2 маддәсенең 3.1 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр һәм эшләрнең база (тармак) исемлекләрен формалаштыру һәм алып бару, дәүләти хезмәтләр һәм эшләрнең ведомство исемлекләрен формалаштыру, алып бару һәм раслау турында һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт учреждениеләре (муниципаль учреждениеләр) тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган дәүләти (муниципаль) хезмәтләр һәм эшләрнең ведомство исемлекләрен формалаштыруга, алып баруга һәм раслауга карата гомуми таләпләр турында» 2014 елның 26 февралендәге 151 санлы карары, шәһәр Уставы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлеген формалаштыру, алып бару һәм раслау тәртибе турында нигезнамәне кушымтада каралганча расларга.

2. 2016 елдан башлап Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләре өчен муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә һәм эшләр башкаруга муниципаль йөкләмәләр формалаштырганда, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән нигезнамә нормалары кулланылуны билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2015 елның 22 сентябрендәге
5382 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлеген формалаштыру, алып бару һәм раслау тәртибе турында
нигезнамә

1. Әлеге нигезнамә Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлеген (алга таба – Муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлеге) формалаштыру, алып бару һәм раслау тәртибен билгели.

2. Башкарма комитетның тиешле муниципаль учреждениеләрнең эшчәнлегенә кураторлык итүче тармак органнары Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлеген формалаштыру, алып бару һәм раслау өчен Башкарма комитетның җаваплы структур бүлекчәләре булып торалар.

3. Муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлеге Башкарма комитет карары белән раслана.

4. Муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлеге билгеләнгән эшчәнлек өлкәләрендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу буенча функцияләрне гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан расланган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр һәм эшләрнең база (тармак) исемлекләре нигезендә формалаштырыла һәм алып барыла.

5. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган һәр муниципаль хезмәт яки эшкә мөнәсәбәтле рәвештә, муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлегенә түбәндәге мәгълүмат кертелә:

1) муниципаль хезмәт яки эш туры килә торган Гомумроссия икътисадый эшчәнлек төрләре классификаторының кодын күрсәтеп, муниципаль хезмәт яки эшнең исеме;

2) учредитель вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органының исеме;

3) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә формалаштырыла һәм алып барыла торган бюджет процессында катнашучылар, шулай ук бюджет процессында катнашучы булып тормаган юридик затлар реестры нигезендә, учредитель вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органының коды;

4) муниципаль учреждениенең исеме һәм муниципаль бюджет процессында катнашучылар, шулай ук бюджет процессында катнашучы булып тормаган юридик затлар реестры нигезендә аның коды;

5) муниципаль хезмәтнең яки эшнең эчтәлеге;

6) муниципаль хезмәт күрсәтү яки эш башкару шартлары (формалары);

7) Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениесенең эшчәнлек төре;

8) муниципаль хезмәтне яки эшне кулланучылар категориясе;

9) сыйфатны (база (тармак) исемлегендә билгеләнгән сыйфатны характерлаучы күрсәткечләр, ә алар булмаганда яки аларга өстәмә итеп, Башкарма комитет карары белән билгеләнгән сыйфатны характерлаучы күрсәткечләр нигезендә) һәм (яки) муниципаль хезмәт (башкарыла торган эш) күләмен һәм аларны үлчәү берәмлеген характерлаучы күрсәткечләрнең исеме;

10) муниципаль хезмәтнең яки эшнең түләүсез яки түләүле булуына күрсәтмә;

11) муниципаль хезмәтне яки эшне муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлегенә кертү яки муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлегенә үзгәрешләр кертү өчен нигез булып торучы Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларының реквизитлары, шулай ук шундый актларның электрон күчермәләре.

6. Әлеге Нигезнамәнең 5 пункты нигезендә һәр муниципаль хезмәт һәм эш буенча формалаштырылган мәгълүмат муниципаль хезмәт һәм эш исемлегенең реестр язуын (алга таба – реестр язулары) барлыкка китерә.

Башкарма комитет тарафыннан формалаштырылган һәм уникаль номер бирелүче расланган реестр язуларының җыелмасы Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлеген барлыкка китерә.

7. Дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматларны үз эченә алган мәгълүмат һәм документлар реестр язуларына кертелми.

8. Реестр язулары Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Реестр язуына кертү өчен мәгълүматны, документларны һәм реестр язуының уникаль номеры структурасын формалаштыру тәртибен кертеп, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт учреждениеләре (муниципаль учреждениеләр) тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган дәүләти (муниципаль) хезмәтләр һәм эшләр исемлекләрен формалаштырганда, алып барганда һәм раслаганда реестр язуларын формалаштыру (үзгәртү) тәртибен раслау турында» 2014 елның 29 декабрендәге 174н санлы боерыгы (алга таба – 174н санлы боерык) белән билгеләнгән тәртиптә Башкарма комитетның тармак органнары тарафыннан формалаштырыла һәм алып барыла һәм Башкарма комитет карары белән раслана.

9. Реестр язуларына кертелә торган мәгълүматны формалаштыру өчен түбәндәгеләр кулланыла:

1) Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләре төрләренә, Яр Чаллы шәһәренең арым муниципаль учреждениеләренә беркетелгән муниципаль хезмәтләрнең һәм эшләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, муниципаль хокукый актлар белән раслана торган якынча исемлеге;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләренең исемлеге;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләренең уставлары һәм фактта башкарыла торган вәкаләтләр нигезендә, Яр Чаллы шәһәренең һәр муниципаль

учреждениесе буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү, эшләр башкару әчтәлеге һәм шартлары (формалары) турында мәгълүмат;

4) Татарстан Республикасында 2016 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының боерыклары белән раслана торган бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәтләр сыйфатын бәяләү күрсәткечләренең якынча исемлеге;

5) Башкарма комитет карары белән раслана торган муниципаль хезмәтләрдән чыгып, 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап муниципаль хезмәтләрнең сыйфат стандартлары составындагы муниципаль хезмәтләр сыйфатын бәяләү күрсәткечләре.

10. Муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлеге 174н санлы боерык белән расланган тәртиптә, Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталы (www.budget.gov.ru) (алга таба – мәгълүмат системасы) аша кереп, «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итү дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында электрон формада формалаштырыла.

Муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлеге Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Федераль дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр һәм эшләрнең база (тармак) исемлекләрен, дәүләти хезмәтләр һәм эшләрнең ведомство исемлекләрен һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт учреждениеләре (муниципаль учреждениеләр) тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган дәүләти (муниципаль) хезмәтләр һәм эшләрнең ведомство исемлекләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләти һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру буенча рәсми сайтта (www.bus.gov.ru) урнаштыру тәртибен раслау турында» 2014 елның 17 декабрендәге 152н санлы боерыгы белән расланган тәртиптә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (www.budget.gov.ru) дәүләти һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру буенча рәсми сайтта (www.bus.gov.ru) урнаштырыла.

11. Реестр язуларына үзгәрешләр әлеге нигезнамәнең 5 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны үзгәртү турында карар кабул ителгәннән соң, эш көннәре белән исәпләнә торган ун көн срокта, 174н санлы боерык белән расланган тәртиптә, Башкарма комитетның тиешле муниципаль учреждениеләр эшчәнлегенә кураторлык итүче тармак органнары тарафыннан кертелә.

12. Реестр язуына кертү өчен мәгълүмат һәм документлар, реестр язуының уникаль номер структурасы 174н санлы боерыкта билгеләнгән кагыйдәләргә туры килергә тиеш.

13. Реестр язулары билгеләнгән тәртиптә Башкарма комитет исеменнән эш итүгә вәкаләтләнгән вазыйфаи затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

14. Башкарма комитетның тиешле муниципаль учреждениеләр эшчәнлегенә кураторлык итүче тармак органнары түбәндәгеләрне тәэмин итә:

1) Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Бюджет яки автономияле учреждениеләрнең учредителе функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган федераль дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), Россия

Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук казна учреждениеләре белән җитәкчелек итүче төп оештыручылар тарафыннан дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр һәм эшләрнең база (тармак) исемлекләренә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр җибәрү тәртибен раслау турында» 2015 елның 26 мартындагы 48н санлы боерыгында (алга таба – 48н санлы боерык) билгеләнгән кагыйдәләр буенча рәсмиләштерелә торган Муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр (алга таба – тәкъдимнәр) әзерләү;

2) тәкъдимнәрне «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә килешенүгә җибәрү;

3) килешенгән тәкъдимнәрне 48 санлы боерык белән билгеләнгән тәртиптә, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу буенча функцияләрне гамәлгә ашыра торган тиешле федераль башкарма хакимият органына карап тикшерү өчен җибәрү.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова